**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Микулино авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Микулино авылы № 110 «18 » 10.2018 ел

«Җир салымы турында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Микулино авыл җирлеге советы карарына үзгәреш кертү хакында (17.08.2015 №145, 09.08.2017 №58 карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешендәге 52 статьясына һәм икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 03.08.2018 № 334-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Микулино авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. «Җир салымы турында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Микулино авыл җирлеге Советы карарына (2015 елның 17 августындагы 145 номерлы карар редакциясендә) түбәндәге эчтәлекле 6 пунктчаның 4 пунктын өстәп, үзгәреш кертергә:
“6) балачактан инвалидлар, инвалид балалар”.

2. Әлеге карар рәсми матбугат басмасында басылып чыккан көннән алып бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә һәм физик затларның җир салымын исәпләүгә бәйле хокук мөнәсәбәтләренә 2015 елның 1 гыйнварыннан кагыла.

3. Әлеге карарны «Маяк» район газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет, финанс, салымнар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис: И.А.Такиулин